КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 21 сентябрь г.Казань № 813

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган һәм мөстәкыйль рәвештә йөрү яки әйләнә-тирәдәге шартларда ориентлашу сәләтен югалткан, медицина ярдәме күрсәтүгә мохтаҗ булмаган затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативын раслау турында” 2017 ел, 18 сентябрь, 702 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган һәм мөстәкыйль рәвештә йөрү яки әйләнә-тирәдәге шартларда ориентлашу сәләтен югалткан, медицина ярдәме күрсәтүгә мохтаҗ булмаган затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативын раслау турында” 2017 ел, 18 сентябрь, 702 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктның икенче – дүртенче абзацларында “558,93”, “567,87”, “578,05” саннарын шул ук эзлеклелектә “567,74”, “582,99”, “599,75” саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган һәм мөстәкыйль рәвештә йөрү яки әйләнә-тирәдәге шартларда ориентлашу сәләтен югалткан, медицина ярдәме күрсәтүгә мохтаҗ булмаган затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативына инфраструктура белән тәэмин ителүдәге

аермалыкларны һәм хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативы мәгънәсенә йогынты ясый торган башка факторларны исәпкә ала торган корректировкалау (төзәтү) коэффициентларын (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Бу карарның гамәле 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 18 сентябрь, 702 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 21 сентябрь, 813 нче
карары редакциясендә)

2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган һәм мөстәкыйль рәвештә йөрү яки әйләнә-тирәдәге шартларда ориентлашу сәләтен югалткан, медицина ярдәме күрсәтүгә мохтаҗ булмаган затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативына инфраструктура белән тәэмин ителүдәге аермалыкларны һәм хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативы мәгънәсенә йогынты ясый торган башка факторларны исәпкә ала торган корректировкалау (төзәтү) коэффициентлары

| Муниципаль берәмлек исеме | Корректировкалау (төзәтү) коэффициенты күләме | | |
|---|---|---|---|
| | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| Азнакай муниципаль районы | 1,731160 | 1,726855 | 1,715463 |
| Әлмәт муниципаль районы | 1,731160 | 1,726855 | 1,715463 |
| Бөгелмә муниципаль районы | 1,731160 | 1,726855 | 1,715463 |
| Алабуга муниципаль районы | 1,731160 | 1,726855 | 1,715463 |
| Зәй муниципаль районы | 1,731160 | 1,726855 | 1,715463 |
| Зеленодольск муниципаль районы | 1,794425 | 1,790956 | 1,780239 |
| Лениногорск муниципаль районы | 1,731160 | 1,726855 | 1,715463 |
| Түбән Кама муниципаль районы | 1,731160 | 1,726855 | 1,715463 |
| Чистай муниципаль районы | 1,731160 | 1,726855 | 1,715463 |
| Яр Чаллы шәһәре | 1,068741 | 1,069075 | 1,064073 |
| Казан шәһәре | 1,068934 | 1,069122 | 1,064039 |

______________________________